КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 апрель г.Казань № 505

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2024 ел, 4 сентябрь, 723 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибендә һәм шартларында:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы икенче – алтынчы һәм уналтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан Министрлыкка ике нөсхәдә тапшырыла.

Сайлап алуда катнашучы Министрлыкка әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы уналтынчы абзацында күрсәтелгән документның икенче нөсхәсен электрон образ рәвешендә тапшырырга хокуклы.»;

әлеге Тәртипнең кушымтасында «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге

технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 16 гыйнвар, 15 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 16 апрель, 232 нче; 2025 ел, 24 декабрь, 1136 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.4 пунктта:

беренче абзацта «субсидияне кире кайтаруны» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтаруны» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«V_{кайтару} = \left(\frac{V_{субсидия} \times k \times m}{n}\right) \times 0{,}1»;$$

җиденче абзацта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

6.6 пунктта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

6.8 пунктта татар текстында «субсидия (субсидиянең бер өлеше)» сүзләрен «субсидия акчасы (субсидиянең бер өлеше)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В. Песошин